**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**08 ноябрь 2019ел** **Чирмешән авылы** **№ 459**

**Чирмешән муниципаль районының 2020 елга юл эшләре программасын раслау турында**

Район торак пунктларының юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, проект-смета документациясе белән юл эшләрен вакытында тәэмин итү максатыннан, район Советының 2013 елның 29 октябрендәге 183 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль юл фондын төзү турында» гы карары нигезендә **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2020 елга Чирмешән муниципаль районының юл эшләре Программасын расларга (муниципаль юл фонды хисабына).
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Кәримов И.И. йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесенең
2019 елның 8 ноябрендәге
459 номерлы Карары белән
расланды

# «2020-2022 ЕЛЛАРГА ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЮЛ ЭШЛӘРЕ» ПРОГРАММАСЫ

## ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2020-2022 елларга Чирмешән муниципаль районының юл эшләре» программасы (алга таба - Программа) |
| Дәүләт заказчысы-Программаның координаторы | Чирмешән муниципаль районының Башкарма комитеты |
| Программаны төп язучылар | Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| Программаның максаты | Чирмешән муниципаль районында икътисад ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм иҗтимагый инфраструктураны алга таба үстерү өчен транспорт комплексын алга таба үстерүне тәэмин итү һәм заманча инфокоммуникацион транспорт инфраструктурасын булдыру |
| Программаның бурычлары | җәмгыять һәм хуҗалык итүче субъектлар мәнфәгатьләрендә җайга салына торган хезмәтләр базарын формалаштыру нигезендә халыкның барлык катламнары өчен тотрыклы эшләп килүче һәм һәркем өчен уңайлы булган бердәм җәмәгать транспорты системасын булдыру;<br>халыкның сыйфатлы һәм куркынычсыз йортүләргә ихтыяҗын канәгатьләндерү, таләп ителә торган техник халәт, үткәрү сәләте, куркынычсызлык һәм юл челтәре конфигурациясенең ышанычлылыгын тәэмин итеп, икътисадның нәтиҗәлелеген һәм конкурентлылыгын арттыру өчен автомобиль юллары челтәрен үстерү;<br>транспорт системасының куркынычсызлыгын арттыру;<br>Чирмешән муниципаль районының транспорт комплексында муниципаль сәясәтне камилләштерү |
| Программаны тормышка ашыру | Программа 2020-2022 елларда тормышка ашырыла.<br>Программаны тормышка ашыру программада күрсәтелгән |

<table>
<tr><td>сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">чараларны максатчан финанслау принцибы буенча башкарыла</td></tr>
<tr><td rowspan="6">Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары еллар буенча</td><td colspan="5">2020 елга Программаны гамәлгә ашыру өчен бюджет ассигнованиеләре күләме 15,800 мең сум тәшкил итә;<br>2021 елга Программа 17,600 мең сум тәшкил итә;<br>2022 елга Программа 18,500 мең сум тәшкил итә.<br>Программаны еллар буенча тормышка ашыру өчен бюджет ассигнованиеләре күләме тәшкил итә:<br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Барлыгы</td><td>Федераль бюджет</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td><td>Муниципаль берәмлек бюджеты акчалары</td></tr>
<tr><td>2020 ел</td><td>15,800</td><td></td><td></td><td>15,800</td></tr>
<tr><td>2021 ел</td><td>17,600</td><td></td><td></td><td>17,600</td></tr>
<tr><td>2022 ел</td><td>18,500</td><td></td><td></td><td>18,500</td></tr>
<tr><td colspan="5">Бюджет йөкләмәләренең күләме тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны эшләгәндә ел саен төгәлләштерелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре</td><td colspan="5">Программа чараларын тормышка ашыру мөмкинлек бирәчәк:<br>муниципаль районның тулаем төбәк продуктының йөк сыйдырышлылыгы дәрәҗәсен киметергә;<br>норматив таләпләргә туры килми торган җирле әһәмияттәге юллар өлешен киметергә;<br>гомуми файдаланудагы юллар челтәренә кадәр каты өслекле юллар булган торак пунктларның чагыштырма авырлыгын арттырырга;<br>район эчендәге маршрут челтәренең үсеш дәрәҗәсен арттырырга;<br>шәһәр читендәге маршрут челтәренең үсеш дәрәҗәсен арттырырга;<br>зарарлы матдәләр чыгару һәм ташлау күләмен киметергә.</td></tr>
</table>